СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82; tukay@tatar.ru

15.11.2024 № вне/3

На №_________ от____________

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставының 46 статьясына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмә нигезендә уздырырга.
3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва итүчеләрдән конкурска документларны 2024 елның «20» ноябреннән 2024 елның «10» декабренә кадәр Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы бинасында түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46 йорт, 103 каб., Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына кандидатураларны карау буенча конкурс комиссиясе 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен эшли, тел. 8 (8552) 70-66-92.

4. Тукай муниципаль районы Советыннан конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләп, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен 6 кешедән торган конкурс комиссиясе составын 2 кушымта нигезендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт формасын 3 кушымта нигезендә расларга.

6. Конкурс комиссиясенә 2024 елның «16» декабренә кадәр Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына тапшырырга.

7. Әлеге карарны «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

9. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Тукай муниципаль районы Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының
2024 елның «15» 11 _____________ 6к/3
номерлы карарына 1 кушымта

# Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе (алга таба - Башкарма комитет Җитәкчесе) вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

2. Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурсның (алга таба - Конкурс) төп максаты булып «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, кадрларны һөнәри, эшлекле һәм әхлакый сыйфатлары буенча сайлап алу һәм эшкә урнаштыру сыйфатын камилләштерү, аларның инициативалылыгын һәм идарә итү һәм методик эшне камилләштерүгә омтылышын стимуллаштыру тора.

3. Конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, муниципаль хезмәтнең баш яки әйдәп баручы вазифаларындагы эшчәнлек юнәлешенә һәм муниципаль хезмәт стажына кимендә ике ел яисә белгечлек буенча кимендә биш ел эш стажына туры килә торган югары һөнәри белеме булган, шулай ук «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясында муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр сыйфатында күрсәтелгән хәлләр булмаган гражданнар ия.

4. Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс уздыру һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәр конкурс уздыру көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

5. Конкурс уздыру турында хәбәрдә күрсәтелә:

1) вазифаның тулы исеме - Башкарма комитет Җитәкчесе;

2) әлеге вазифаны биләүгә дәгъва итүчегә карата куела торган таләпләрне үз эченә алган Конкурс уздыру шартлары;

3) Конкурсны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

4) документларны кабул итү урыны һәм вакыты;

5) Башкарма комитет Җитәкчесе белән төзелә торган контракт проекты;

6) Конкурс турында тулырак мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта, электрон адрес).

6. Конкурс ике этапта уздырыла. Беренче этап конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерүне бастырып чыгаруны үз эченә ала һәм тапшырылган документлар нигезендә конкурс комиссиясе кандидатларны Конкурста катнашуга кертү турында карар кабул итә.

Конкурста катнашырга теләүче затлар түбәндәге документларны тапшыралар:

1) 4 х 6 зурлыктагы фотографияне теркәп, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, автобиография;

2) паспортның яки аны алмаштыручы документның күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

3) кирәкле һөнәри белемне, эш стажын һәм квалификациясен раслый торган документлар;

4) хезмәт кенәгәсенең яки гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документның күчермәсе;

5) һөнәри белем турында, шулай ук, граждан теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документларның нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәтләре тарафыннан таныкланган күчермәләре;

6) муниципаль хезмәткә кергән елга кадәрге ел өчен керемнәр һәм чыгымнар турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре һәм чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

7) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яки аны узуга комачаулый торган чире булмау турында документ.

Гариза биргән затка документларны алу турында исемлеге һәм аларны алу датасы күрсәтелгән расписка бирелә.

Тапшырылган документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Граждан, Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасына квалификация таләпләренә туры килмәү сәбәпле, шулай ук муниципаль хезмәт турында законнарда муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә, конкурста катнашуга кертелми.

Конкурста катнашуга кертүдән баш тарткан очракта, граждан әлеге карарга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданны Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

8. Конкурсның икенче этабында конкурс комиссиясе утырышларында фикер алышу һәм кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелә.

9. Конкурс Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән гыйбарәт.

Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны белем, граждан яки башка дәүләт һәм муниципаль хезмәт узу, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында алар тапшырган документлар, муниципаль хезмәткә керүгә комачаулый торган авыруның булмавы турында медицина учреждениесе бәяләмәсе, шулай ук граждан муниципаль хезмәткә кабул ителә алмый торган нигезләрнең булмавын билгеләргә мөмкинлек бирә торган башка документлар нигезендә, кандидатларның һөнәри һәм шәхес сыйфатларын бәяләүнең федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган ысулларын кулланып, конкурс процедуралары нигезендә, кандидатларның үз программаларын тәкъдим итүен, шәхси әңгәмәне дә кертеп бәяли.

10. Әгәр Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасына квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса,

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы конкурс комиссиясенең Конкурсны узмаган дип тану турында беркетмәсе нигезендә кабат Конкурс үткәрү турында карар кабул итә.

11. Конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карарлары катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

12. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында мәгълүмат конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы сессиясенә тапшырыла.

13. Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләп кую «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карары белән рәсмиләштерелә. Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турында карар массакүләм мәгълүмат чараларында бастырыла.

14. Сайланган Башкарма комитет Җитәкчесе белән «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы вазифасын башкаручы контракт төзи.

15. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс уздырыла торган урынга бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һ.б.) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабына башкарыла.

Тукай муниципаль районы Советының
2024 елның «15» 11 вн/3
номерлы карарына 2 кушымта

**Конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Габдуллин Айрат Салават улы | Тукай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, **комиссия рәисе** |
| Сурова Ога Викторовна | Тукай муниципаль районы Советы депутаты, **комиссия рәисе урынбасары** |
| Петров Григорий Николаевич | Тукай муниципаль районы Советы депутаты, **комиссия секретаре** |